СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2019 с. Сарманово №161

Татарстан Республикасының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль законының шәһәр, авыл җирлеге, муниципаль район, шәһәр округы, шәһәр эчендәге бүленешләре белән шәһәр округы, шәһәр эчендәге район җирле үзидарә органнарының кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыруга хокуклары өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июленнән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы», 2018 елның 22 октябреннән 11-09/11409 номерлы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы хаты нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына 1 нче номерлы кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин

Сарман муниципаль районы
Советы карарына
кушымта №1
18.02.2019 ел № 161

**Татарстан Республикасының “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

1. 7нче статьяның 1нче кисәген түбәндәге эчтәлектәге 12 пункт белән тулыландырырга:

«12. “Кулланучылар хокукларын яклау турында” 1992 елның 7 феврале 2300-1 номерлы Россия Федерациясе законы белән каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.